

Әхмәт ДУСАЙЛЫ

# «Мин бик яшьли шагыйрь калдым...»

***Әхмәт Дусайлы** (Әхмәтҗан Хәсәнҗан улы Хәмәдишин) 1949 елның 20 августында Татарстанның Мөслим районы Дусай авылында туа. Шагыйрь, прозаик, публицист. Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби бүләк иясе, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Мөслимдә яши. Каләмдәшебез бу айда күркәм юбилеен каршылый. Аны редакция коллективы исеменнән тәбрик итәбез. Иминлек, озын гомер, каләм ныклыгы һәм сүрелмәс иҗат дәрте телибез.*

## Үзеңә кайт

Күңелеңә шикле уйлар килсә,
уйларыңа кереп олаксаң,
Раббың тавышын бер ишетер өчен,
үз-үзеңә, дустым, колак сал.
«Пәйгамбәр»ләр бик күбәеп китеп,
кыйблаңны син әгәр югалтсаң,
үзеңә кайт, бары үзеңә кайт,
үз-үзеңә, дустым, колак сал.
– Син акыллы.
Яки:
– Исәр, – диләр.
Бу җәһәттән минем шигем бар:
үзең сизмәгәндә, син дә даһи,
үзең сизмәгәндә – пәйгамбәр.
Күңелеңә шикле уйлар килсә,
караңгыга әгәр юлыксан,
Раббың тавышын бер ишетер өчен,
үзеңә кайт, үзеңә колак сал...

* * *

Ходай мине үзе ярлыкасын,
Кыйбланы мин бүген бутадым:
синең якка карап сәҗдә кылдым,
башны ора-ора еладым.

Башны ора-ора елаганны
ярый әле үзең күрмәдең.
Тик...
Күрсәң дә...
эрнер иде микән йөрәгең?

Синең йөрәк, беләм, дулкынланмый,
тыныч кына сөя башканы.
Тыныч кына карап калырсыңмы,
елый-елый дога кылырсыңмы
күргәч минем Күккә ашканны?

* * *

Бәргәләнә бәгырь, бәргәләнә,
якты эзләп төннәр эченнән.
Әллә, юкса, күзем сукыр микән,
әллә, юкса, дөнья күченгән?..
Әллә, юкса, Кояш капланганмы –
асты өскә килгән Җиһанның,
тау дигәнем әллә чокырмы соң,
менәм диеп аска төшәмме?
Әллә Мәхшәр үзе шушы микән,
сур өргәнне сизми калдыммы?
Мәетләрме, тере кешеләрме
камап алган тирә-ягымны?
Мин ялгызмын –
алар тарткалаша,
мин сукырмын –
алар күрәләр,
әллә ниләр табып сөенәләр,
бармак төртеп миннән көләләр...
Бәргәләнә бәгырь, сыкрана җан,
таулар тетри дәһшәт-тынлыктан...
Бу Кояш соң әллә капланганмы,
әллә инде мине оныткан?..
Ник ачылмый офыкта бер сызык,
бер мизгелгә генә, бер мәлгә?
Бу Җиһанның, салкын бу дөньяның
үги баласымы мин әллә?
Бәргәләнә бәгырь, бәргәләнә,
якты сорый җаным, нан сорый,
рухый уразадан чыга алмый,
үзен-үзе көчкә асырый.
Бәргәләнмә, бәгырь, сыкранма, җан,
Раббыңнан сора тик син иман!..

* * *

Сал битлегең, әйдә, бер сәгатькә,
ял ит бераз тормыш шавыннан.
Күреп торам: синең дә бит күңел
ихлас сөйләшүне сагынган.
Ихлас сөйләшүләр – җанга дәва,
кузгатса да йөрәк ярасын.
Уйламыйча сөйлә, буталып бет,
сайламыйча агын-карасын.
Ялгышудан курыкмыйча сөйлә –
мин, төзәтеп, сине кызартмам.
Дөрес сүзләр таба алмас булсаң,
озын итеп сөйлә, ерактан.
Сөйлә
сине кемнәр рәнҗеткәнен
арка каккан булып, елмаеп.
Сине дә бит кемдер коча-үбә
кыйнап киткәндер лә, мөгаен?
Сине дә бит кемдер якын иткән –
чәнечкеңә кулын канаткан,
кулын гынамы соң, йөрәген дә
килеп чәнечкәндер кабаттан...
Сал битлегең, әйдә,
башта син ач,
мин дә чишенермен аннары...
Хәер... дустым,
салмыйк битлекләрне,
күрсәтешмик гарип җаннарны...

## Язмышыма

Минем язмыш – үги ана кебек,
мине шундый итеп ярата:
елмая да, ал чәчәкләр өзеп,
башка балаларга тарата.

Язмышымның саллы йодырыгы
дөмбәсли дә мине дөмбәсли,
әллә инде ялгышлардан саклый,
туры юлдан гына йөрмәс, ди.

Юлларымны үзем сайламыйм шул,
син бит, Язмыш, үзең йөртәсең,
абындыра-нитә йөгертәсең,
егылмасам, арттан төртәсең,
үзең тагын тартып торгызасың
тагын төртеп егар өченме?...
Чыныктыруыңмы мине шулай,
сыныйсыңмы әллә көчемне?

Ниләр генә миңа күрсәтсәң дә,
карышырга синә җыенмыйм,
үҗәтләнеп һаман үрмәлимен
егылып, кабат торыр өчен мин.

Күпме генә мине кыйнасаң да,
ияләштем инде сиңарга.
Ходай миңа ике гомер бирсә,
килерсең бит кабат кыйнарга.

* * *

Хыялымда синең күзгә карыйм –
чайпалырга торган күзләргә.
Чайпалдырмый, яшьләндерми генә
үбәргә дә иде үбәргә!

Хыялымда синең күзгә карыйм
сагыш-моңга чумып йөргәндә.
Бәгырьләрем суырылып килә –
ничек кенә шуңа түзәргә?!

Хыялымда синең күзгә карыйм
сәхраләрдә ялгыз йөргәндә.
Чайпалырга торган күзләреңдә
йөзәргә дә иде, йөзәргә!

## Кайту

Менә тагын кайттым яшьлегемә,
сөенә-сөенә кайттым,
күпме эзләп йөреп табалмаган
бәхетемне таптым.

Менә тагын аның җылы кулын
учларымда тотам.
Ләкин аңа әйтер сүзләремне
йөрәгемә йотам.

Менә тагын иске сукмакларны
мин киңәйтеп үтәм.
Тик колакта инде яңгырыйдыр
мәхәббәткә матәм...

Менә тагын соңгы айрылышу
очрашмаска бүтән.
Инде, Яшьлек, кабат кайталмамдыр,
бөтенләйгә китәм...

Менә тагын
яшьлегемә
кайттым...

## Китәм инде

Китәм инде.
Җилләр!
Миннән башка гына исегез.
Сөйгәнемә берүк
сәламемне генә илтегез.

Китәм инде.
Кояш!
Миннән башка гына атарсың.
Тәрәзәдән кереп,
сөйгәнемне кочып ятарсың.

Китәм инде.
Көннәр!
Миннән башка гына үтәрсез.
Сөйгәнемне...
бәлки...
мин булмагач, үксез итәрсез...

* * *

Карурманга берьялгызың кермә,
кала күрмә анда адашып.
Синең өчен утка керер булсын,
ышанычлы булсын юлдашың.

Юлларыңда гөлләр чәчәк атсын,
Баш очыңда кошлар сайрасын.
Гел елмаеп, гел бәхеттә үткәр
еллар белән еллар арасын.

Зәһәр җилләр әгәр юлың киссә,
авырлыклар әгәр каныкса,
кояш булып сине җылытырдай
чын дусларың барын онытма!

* * *

Шәм кабызып, тәрәзәмә куйдым,
бәлки бер дус аны күрер, дип,
күреп, бәлки, ишегемне шакыр,
ятим җанның хәлен белер, дип.

Шәмем инде янып бетеп бара,
өмет сүнеп бара күңелдә.
Шәм кимегән саен, өмет җебе
Кыскара әйләнеп күмергә.

Зәгыйфь ялкын калтыранып куя
тойган саен минем аһымны.
Ятим җанның хәлен белерләрме,
берәү килеп ишек шакырмы?..

## Карга

Сандугачлар әле җәйне көтә,
ә каргалар инде биредә.
Кулын артка куйган картлар кебек
кара җиргә карап йөриләр.

## «Бала»

*(Леон Озолдан)*

Ах та ух килә бер хатын,
улы югалган анын,
постовойдан елап сорый:
– Табыгыз, – ди, – баламны! –
Аннан башка нишләрмен мин,
ансыз үләм инде, – ди.
– Каян табарга соң аны,
төскә-биткә ул нинди?
– Үзе шундый юаш кына,
оялчан гына бала,
буйга озын, үзе ябык,
сакал-мыегы... кара.

## Хыяллар

Хыяллар, хыяллар...
Мамыктай җиңел сез.
Сезсез бик күнелсез...
Хыяллар, хыяллар,
кош кебек очасыз,
егылып төшәсез...

* * *

Күңел – лупа. Фикерләрне
я тарата, я җыя.
Җыйган чакта, зур фикерләр
Бер ноктага да сыя.

## Шагыйрь

Мин бик яшьли шагыйрь калдым –
үзем белгәннән бирле.
Шәрә җаным җиде җилдә
җылы тапмый тилмерде.

Җиде күгәрчен чукыды
чәүкә дип белеп мине.
Әллә юкса, бөртек ярма
чәүкәгә кирәкмиме!

Болдырның бозлы тактасын
ялан тәпи таптадым.
Нинди генә хәлдә дә мин
шагыйрьлегем сатмадым.

Аллаһның әмере белән
шагыйрьлек иңгән иде.
Аллаһ Үзе шагыйрь итеп
җибәрде Җиргә мине:
милләтемне уятырга
үлем йокыларыннан,
илемне чистартырга
җаһиллек пычрагыннан.

Керләнеп-пычрап бетсәм дә,
җанымны тапламадым,
алтын-көмешкә алданып
мөртәтне якламадым.

Гомеремне уздырсам да
Бер дәрвиш рәвешендә,
бәхетле вә рәхмәтле мин
Җиргә Җибәрүчемә.

**2010, 26 апрель.**